ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 29 гыйнвары Тимәш авылы №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 9678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләр бәясен раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорты, җирле үзидарә бинасы, Киров урамы, авыл мәдәният йортының 2-бинасы, Нефтепроводчиклар урамы, Ромашкино РНУ БПО утырышларының 20-залы, Киров ур., 1А-йорты «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Урман ур., 20, Урман ур., 33 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниипаль районы
« Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

Х.Х.Сөләйманова

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 658,54 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып килү | 1 838,93 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |

---

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Җирләү һәм күмү эше турында» ФЗ-8 12 маддәсе нигезендә күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне тәрү; | 1 207,32 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 451,21 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1 838,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |